СОВЕТ БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

_14.04.2023____ Баулы шәһәре № 177

Баулы муниципаль районы Советының «Баулы муниципаль районы Советы Регламенты турында» 2005 елның 13 декабрендәге 3/2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 21.12.2021-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль районы Советының «Баулы муниципаль районы Советы Регламенты турында» 2005 елның 13 декабрендәге 3/2 номерлы карарына (2010 елның 25 февралендәге 234 номерлы, 2012 елның 25 февралендәге 113 номерлы, 2014 елның 4 апрелендәге 200 номерлы, 2020 елның 29 июлендәге 272 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

13 статьяның 2 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

60 статьяның 1 пунктының 13 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район Советының җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы Рәисе И.И. Гозәеров